**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2025 елның «12» мартыннан — № 66

**Россия Федерациясе торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

РФ Хөкүмәтенең «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт дип ,һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакындагы» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары һәм РФ Торак кодексының 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча, составын 1 нче кушымтага нигезләп, ведомствоара комиссия төзергә.

2. Россия Федерациясе торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссиясе тырында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга;

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе торак фондының, федераль милектә булган

күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 елның 26 маендагы 221 номерлы карарын (2016 елның 03 августындагы 301 номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 508 номерлы, 2017 елның 09 мартындагы 128 номерлы, 2017 елның 07 июнендәге 268 номерлы, 2017 елның 14 сентябрендәге 461 номерлы, 2018 елның 23 мартындагы 130 номерлы, 2018 елның 13 сентябрендәге 429 номерлы, 2019 елның 09 гыйнварындагы 1 номерлы, 2019 елның 27 августындагы 216 номерлы, 2020 елның 17 гыйнварындагы 9 номерлы, 2020 елның 09 сентябрендәге 224 номерлы, 2021 елның 20 февралендәге 80 номерлы, 2021 елның 19 апрелендәге 189 номерлы, 2022 елның 21 апрелендәге 125 номерлы, 2024 елның 18 гыйнварындагы 14 номерлы, 2025 елның 18 февралендәге 40 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда httpps://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «12» мартыннан
66 номерлы карарына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия составы

Ведомствоара комиссия җитәкчесе:

| | | |
|---|---|---|
| Габетдинов Ренат Хәлфәт улы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) |

Ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Попкова Наталья Владимировна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |

Ведомствоара комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Кәбирова Диләрә Нәкыйп кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Нуретдинова Алия Рөстәм кызы | - | Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск һәм Яңа Чишмә районнарында территориаль бүлеге эксперт-белгече |
| Пузикова Нина Ивановна | - | Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды бүлегенең Татарстан Республикасы буенча Яңа Чишмә районында клиентлар хезмәте (бүлек хокукларында) җитәкчесе |

| | | |
|---|---|---|
| Филатова Светлана Сергеевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы |
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - | карала торган мәсьәләгә карап |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «12» мартыннан
66 номерлы карарына
2 нче кушымта

# Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Торак фондының, федераль милектә булган күп фатирлы йортларның һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча комиссия (алга таба - комиссия) тиешле мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә вәкаләтле даими эшләүче орган булып тора.

1.2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Россия Федерациясе Торак кодексына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт дип ,һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакындагы» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан биналарны һәм күпфатирлы йортларны бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максаты белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен

яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү өчен төзелгән.

1.4. Комиссия Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә һәм бетерелә.

1.5. Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

1.6. Комиссиядә эшенә киңәшле тавыш хокукы белән торак урын милекчесе (аның вәкаләтле заты) җәлеп ителә.

1.7. Комиссия юридик зат булып тормый.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып аның бинаны торак бина, торак бинаны гражданнарга яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү тора.

2.2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан торак биналарның яраклылыгы/яраксызлыгы фактын билгеләү турында белешмәләрне тикшерүне һәм җибәрүне оештыру, шул исәптән Россия Федерациясе Пенсия һәм Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары аша соравы буенча.

## 3. Комиссиянең вәкаләтләре

3.1. Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында аның рәисе күрсәтмәсе буенча эш итүче рәисе һәм комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Комиссия эшенә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре вәкилләрен, барлык милек формасындагы торак-эксплуатация оешмалары вәкилләрен (килешү буенча), шулай ук конкрет мәсьәләне хәл итүдә кызыксынучы башка затларны җәлеп итәргә.

3.1.2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләреннән, юридик һәм физик затлардан комиссиягә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны тиешле тәртиптә соратырга һәм алырга.

3.1.3. Тиешле органнарга ачыкланган торак биналарның тиешенчә тотылмау, үз белдеге белән яңадан корылу һәм (яисә) торак урыннарын яңадан планлаштыру фактлары буенча законнар белән билгеләнгән чаралар күрү өчен материаллар җибәрергә.

3.1.4. Комиссия тикшерү үткәрү кирәклеге турында карар кабул иткән очракта, милекчедән яисә ул вәкаләт биргән заттан билгеләнгән көнне һәм вакытта бинага тоткарлыксыз керүне тәэмин итүне таләп итәргә.

3.2. Милекче яисә вәкаләтле зат тикшерүне уздыру өчен комиссиянең законлы һәм нигезләнгән таләпләрен үтәмәгәндә, комиссия тиешле мәсьәләне караудан баш тартырга хокуклы.

## 4. Комиссиянең эш һәм карарлар кабул итү тәртибе

4.1. Комиссия торак урын милекчесенең, бәяләнә торган мөлкәткә карата милекченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының гаризасы нигезендә, хокукка ия булучының яисә гражданның (яллаучының) йә үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча дәүләт күзәтчелеге (контрольлек) органнарының бәяләмәсе нигезендә торак урынның нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли һәм Нигезләмәдә каралган тәртиптә карарлар кабул итә.

4.2. Комиссиянең эш формалары булып тикшерү, бәяләү һәм комиссиянең утырышларын уздыру тора.

4.3. Комиссия утырышлары кирәк саен комиссия рәисе (аның юклыгында - рәис урынбасары) тарафыннан чакырыла.

4.4. Утырыш, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

4.5. Утырышны комиссия рәисе (алга таба - рәис), ә ул булмаган очракта - комиссия рәисе урынбасары (алга таба - рәис урынбасары) алып бара.

4.6. Комиссия рәисе:

4.6.1. Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итә.

4.6.2. Утырышта хәлиткеч тавыш хокукы белән катнаша.

4.6.3. Утырышның көн тәртибен формалаштыра.

4.6.4. Карала торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан таныша.

4.6.5. Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

4.6.6. Комиссия документларын, шул исәптән беркетмәләрне, карарларны, бәяләмәләрне, актларны имзалый.

4.6.7. Кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерүне оештыра.

4.7. Комиссия рәисе урынбасары:

4.7.1. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын башкара.

4.7.2. Утырышта хәлиткеч тавыш хокукы белән катнаша.

4.7.3. Утырышлар уздыруны, шулай ук аның утырышларында мәгълүмати-аналитик һәм башка материалларны карау өчен кирәкле документлар әзерләүне оештыра.

4.7.4. Башка хокукларга ия һәм комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының вазыйфаларын башкара.

4.8. Комиссия әгъзалары:

4.8.1. Комиссия утырышының көн тәртибенә тәкъдимнәр кертәләр.

4.8.2. Карала торган мәсьәләләр буенча материаллар белән атанышалар.

4.8.3. Утырышта хәлиткеч тавыш хокукы белән катнашалар.

4.8.4. Комиссия вәкаләтләрендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр.

4.8.5. Комиссия һәм аның рәисе йөкләмәләрен үтиләр.

4.8.6. Утырышта карау өчен мәсьәләләрне әзерләүдә катнашалар һәм аның карарларын үтәү, аларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыралар.

4.8.7. Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү буенча башка гамәлләрне башкаралар.

4.9. Комиссия секретаре:

4.9.1. Утырыш беркетмәсен алып бара, 1 нче кушымтадагы форма буенча бәяләмәләр проектларын, 2 нче кушымтадагы форма буенча комиссия актларын, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле мәсьәләләр буенча карарлары проектларын әзерли.

4.9.2. Башка хокукларга ия һәм комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының вазыйфаларын башкара.

4.10. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

4.11. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.12. Кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, комиссия әгъзасы язма рәвештә үзенең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә (бәяләү актына) мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.

4.13. Бинаны торак бина, торак бинаны гражданнарга яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану һәм күпфатирлы йортны (Россия Федерациясе торак фондының һәм федераль милектәге күпфатирлы йортларның торак урыннарыннан тыш) авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында карар җирле үзидарә органы тараыфыннан Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары рәвешендә кабул ителә.

4.14. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектларын әзерләү; аларны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле структур бүлекчәләре белән килештерүне комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

4.15. Мөрәҗәгать итүчегә һәм башка кызыксынучы затларга кабул ителгән карар турында тиешле карарны кулына бирү яки шундый карарны гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша заказлы хат белән җибәрү юлы белән хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүче белән электрон рәвештә хезмәттәшлек иткән очракта, карарны электрон формада җибәрә. Карар электрон рәвештә җибәрелгән очракта, шулай ук карарның нөсхәләре мөрәҗәгать итүченең тиешле гарызнамәсе буенча кәгазь рәвешендә бирелә (җибәрелә).

4.16. Комиссия тәкъдим ителгән материалларны карауга экспертларның махсуслаштырылган оешмаларын җәлеп итәргә хокуклы.

4.17. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «12» мартыннан
66 номерлы карары белән расланган
Россия Федерациясе Торак
фондының, федераль милектә
булган күп фатирлы йортларның
һәм Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы
территориясендә муниципаль торак
фондының торак урыннарын бәяләү
буенча ведомствоара комиссия
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт дип ,һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында

БӘЯЛӘМӘ

№ ______________________________ ______________________________
(дата)

______________________________________________________________________
(бинаның урнашу урыны, шул исәптән торак пункт һәм урам исемнәре, йорт һәм фатир номерлары)

Ведомствоара комиссия ______________________________

______________________________________________________________________,
(кем тарафыннан билгеләнгән, федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы исеме, комиссияне чакыру турында карарның датасы, номеры)

Рәис ______________________________________________

______________________________________________________________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм комиссия
әгъзалары составында ______________________________

______________________________________________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар катнашында ______________________________

______________________________________________________

______________________________________________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

торак милекчесен яки аларга вәкаләтле затны кабул итү

______________________________________________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

каралган документлар нәтиҗәләре буенча ______________________________

______________________________________________________
(документлар исемлеге китерелә)

тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән ведомствоара комиссия акты нигезендә эш,

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________
(тикшерү актыннан алынган бәяләмә китерелә (тикшерү үткәрелгән очракта) яки ведомствоара комиссия карары нигезендә тикшерү үткәрелмәгәнлеге күрсәтелә)

турындагы бәяләмәне
кубул итте ______________________________

______________________________________________________
(торак урыны, торак урыны яшәү
өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортның авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне бәяләү буенча ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән бәяләмәне нигезләү китерелә)

Бәяләмәгә кушымта:

а) каралган документлар исемлеге;

б) бинаны тикшерү акты (тикшерү үткәрелгән очракта);

в) ведомствоара комиссия тарафыннан соратып алынган башка материаллар исемлеге;

г) ведомствоара комиссия әгъзаларының аерым фикере:

______________________________________________________________________.

Ведомствоара комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| ________________________ (имза) | ____________________________________ (ф.и.о.) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары

| | |
|---|---|
| ________________________ (имза) | ____________________________________ (ф.и.о.) |
| ________________________ имза) | ____________________________________ (ф.и.о.) |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «12» мартыннан
66 номерлы карары белән расланган
Россия Федерациясе Торак
фондының, федераль милектә
булган күп фатирлы йортларның
һәм Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы
территориясендә муниципаль торак
фондының торак урыннарын бәяләү
буенча ведомствоара комиссия
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Бинаны (күпфатирлы йортны) тикшерү
АКТЫ

№ ____________________ ____________________
(дата)

____________________
(бинаның (күпфатирлы йортның) урнашу урыны, шул исәптән торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номерлары)

Ведомствоара комиссия ____________________

____________________,
(кем тарафыннан билгеләнгән, федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы исеме, комиссияне чакыру турында карарның датасы, номеры)

Рәис ____________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм комиссия
әгъзалары
составында ____________________
(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар катнашында ____________________

(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

торак милекчесен яки аларга вәкаләтле затны кабул итү

(ф.и.о., били торган вазыйфасы һәм эш урыны)

гариза буенча бинаны (күпфатирлы йортны) тикшерде

гариза бирүченең реквизитлары: ф. и. о. һәм адрес - физик зат өчен, оешманың исеме һәм билгән вазыйфасы - юридик зат өчен)

һәм бинаны (күпфатирлы йорты) тикшерү буенча әлеге акт төзеде

(адресы, бинаның нинди булуы, кадастр номеры, файдалануга тапшыру елы)

Төзелеш корылмалары, бинаның инженерлык системалары, җиһазлар һәм механизмнар һәм бина янындагы торак бинаның торышын кыскача тасвирлау

Күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү турында белешмәләр

Үткәрелгән инструменталь контроль һәм башка төр контроль һәм тикшеренүләр нәтиҗәләрен бәяләү

(контроль (сынау) кем тарафыннан, нинди күрсәткечләр буенча, нинди фактик мәгънәләр алынган)

Ведомствоара комиссия киңәшләре һәм даими яшәү өчен иминлек тәэмин итү яки нормаль шартлар булдыру өчен кирәкле тәкъдим ителә торган чаралар

Бинаны тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе

Актка кушымта:

а) инструменталь контроль нәтиҗәләре;

б) лаборатор сынаулар нәтиҗәләре;

в) тикшеренүләр нәтиҗәләре;

г) махсуслаштырылган оешмалар экспертларының бәяләмәләре;

д) ведомствоара комиссия карары буенча башка материаллар.

Ведомствоара комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| (имза) | (ф.и.о.) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары

| | |
|---|---|
| (имза) | (ф.и.о.) |
| (имза) | (ф.и.о.) |
| (имза) | (ф.и.о.) |
| (имза) | (ф.и.о.) |